РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**МУСЛЮМОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**

**СОВЕТ МУСЛЮМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**МӨСЛИМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

*№__1__* *01. 06.2017 ел*

**«2017 елга Мөслим авылында уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» муниципаль программасын раслау турында» Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитетының карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү хакында**

Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын үтәү максатыннан, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы нигезендә муниципаль берәмлекне үстерү программалары турында фикер алышуда, **КАРАР БИРӘМ:**

1. «2017 елларга Мөслим авылында уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» муниципаль программасын раслау турында» Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитетының карар проекты буенча халык алдында тыңлаулар үткәрүне билгеләргә (1-нче кушымта).

2. Билгеләргә:

2.1. Ачык тыңлаулар уздыру датасы һәм вакыты - 21.06.2017 ел, 10.00 сәгатьтә;

2.2. Үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Мөслим авылы, Пушкин ур., 44 нче йорт адресы буенча урнашкан «Мизгел» яшьләр үзәге;

2.3. Фикер алышу мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр белдерелергә мөмкин булган адрес гавами тыңлауларда катнашырга гаризалар бирергә: Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Мөслим авылы, Пушкин ур., 43 йорт (эш көннәрендә - 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр);

2.4. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты - 21.06.2017 кадәр.

3. Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитетына (М.Д.Шәймөхәммәтовка) гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән вакытта гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми порталында веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://muslumovo.tatarstan.ru/һәм «Авыл утлары» район газетасында бастырыргаhttp://muslumovo.tatarstan.ru/

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Мөслим авыл җирлеге башлыгы** **Р.Х. Муллин**

Мөслим авыл җирлеге
башлыгының 2017 елның
1 июнендәге 1нче карарына
1 нче кушымта

**«2017 елга Мөслим авылында уңайлы шәһәр мохите формалаштыру»**
**муниципаль программасын раслау турында**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим авылы территорияләрен төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.04.2017 елдагы карарын үтәү йөзеннән № 511

Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына Россия Федерациясе субъектлары дәүләт программаларына һәм заманча шәһәр мохитен формалаштыруның муниципаль программаларына ярдәм итүгә федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында һәм 2017 елда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фондыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына исәпләнгән бюджет тәэминаты дәрәҗәсе 1 дән югарырак булган субсидияләрне Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына бүлеп бирелә торган субсидияләрне бүлүне раслау турында, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программаларына һәм уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру буенча муниципаль программаларга ярдәм йөзеннән», Мөслим авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Мөслим авылында 2017 елга уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» муниципаль программасын раслаарга (1-нче кушымта).
2. Югарыда күрсәтелгән адреслы программаны гамәлгә ашыруда җәлеп ителгән оешмалар җитәкчеләренә әлеге программага кертелгән чараларны алдан күрергә һәм аларның үтәлешен тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе М.Д. Шәймөхәмәтов

Мөслим авыл җирлеге
башлыгының 2017 елның
1 июнендәге 1нче карарына
1 нче кушымта

«2017 елга Мөслим авылында уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» муниципаль программасы

## I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге муниципаль программа «2017 елга Мөслим авылында уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» (алга таба-Программа) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясында беркетелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.04.2017 елдагы 511 номерлы карары нигезләмәләрен үтәү кысаларында эшләнде «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына Россия Федерациясе субъектлары дәүләт программаларына һәм заманча шәһәр мохитен формалаштыруның муниципаль программаларына ярдәм итүгә федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында һәм 2017 елда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фондыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына исәпләнгән бюджет тәэминаты дәрәҗәсе 1 дән югарырак булган субсидияләрне Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына бүлеп бирелә торган субсидияләрне бүлүне раслау турында, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программаларына һәм уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру буенча муниципаль программаларга ярдәм йөзеннән эшләнгән».

Программаның заказчысы һәм җаваплы башкаручысы булып Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитеты тора.

Программада Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитеты буйсынуындагы учреждениеләр һәм оешмалар, ишегалды территориясе программа чараларында катнаша торган күпфатирлы йортларның милекчеләре, шулай ук махсус подряд оешмалары катнаша.

## II. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Әлеге Программаның төп максатлары һәм бурычлары түбәндәгеләр:

- гамәлдәге төзелеш шартларында гражданнарның яшәү өчен имин һәм уңайлы шартлар тудыру;
- Мөслим авылының ишегалды территорияләрен төзекләндерүнең дәрәҗәсен күтәрү;
- кызыксынучы гражданнарның, оешмаларның Мөслим авылындагы күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруга җәлеп итү дәрәҗәсен арттыру;
- күпфатирлы йортларның йорт яны территорияләрендә яңа ял итү урыннарын оештыру һәм булганнарын торгызу;

- йорт эчендәге территорияләрдә урнашкан төзекләндерү объектларының сакланышын һәм куллану сыйфатын арттыруны тәэмин итү.

## II. Программаның төп чаралары

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру барышында Мөслим авылында күп фатирлы йортларның ишегалды территорияләрен төзекләндерү буенча чаралар оештыру һәм үткәрү күздә тотыла, шул исәптән түбәндәге чаралар:

- кече архитектура формаларын төзекләндерү;
- җәяүлеләр өчен юл салу.

Югарыда күрсәтелгән чараларның нәтиҗәсе - халыкның яшәү уңайлылыгын һәм куркынычсызлыгын арттыру.

Билгеләнгән чараларны гамәлгә ашыруның планлаштырылган срогы - 2017 ел

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Әлеге Программа чараларын финанслауның гомуми күләме 12 000 мең сум тәшкил итәчәк.

Программада катнашучы ишегаллары исемлеге, ишегалды территорияләрен төзекләндерү буенча планлаштырылган эшләр бәясе һәм төрләре әлеге программага кушымтада чагылдырылган.

«2017 елга Мөслим авылында уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» муниципаль программасына кушымта

2017 елга программада катнашучы ишегаллары исемлеге

| Адрес | Эшләрнең атамасы | Үлчәү берәмлеге | Саны | Бәясе, мең сум |
|---|---|---|---|---|
| **Пушкин урамы** | **Ишегалды территориясен төзекләндерү** | | | **7 000** |
| | МАФлар | комплект | 1 | 1 000 |
| | Җәяүлеләр өчен юллар салу | кв.м | 2400 | 6 000 |
| **Вахитов урамы** | **Ишегалды территориясен төзекләндерү** | | | **5 000** |
| | МАФлар | комплект | 1 | 1 000 |
| | Җәяүлеләр өчен юллар салу | кв.м | 1600 | 4 000 |
| **Барлыгы** | | | | **12 000** |